ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.03.2015 Казань ш. №3-5/э

***«Энерготранзит» ҖЧҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифлар билгеләү турында***

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ санлы Федераль законга, «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, тарифлар буенча Федераль хезмәтнең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынучы тарифларны һәм бәяләрне исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 санлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Энерготранзит» ҖЧҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергияне тапшыру хезмәтенә индивидуаль тарифларны карар үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр, календарь чорларына бүлеп, әлеге карар кушымтасына туры китереп билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
2 нче кушымта
31.03.2015 № 3-5/э

Карар үз көченә кергән көннән алып, 2015 елның 31 декабренә кадәр, календарь чорларына бүлеп, «Энерготранзит» ҖЧҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифлар

НДСтан тыш

| № п/п | Челтәр оешмалары атамалары | карар үз көченә кергән көннән алып, 2015 елның 30 июненә кадәр, | | | 01 июль 2015 елдан 31 декабрь 2015 елга кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | электр челтәрләрен карап тотуга ставка | технологик чыгымнар (югалтулар) өчен түләүгә ставка | | электр челтәрләрен карап тотуга ставка | технологик чыгымнар (югалтулар) өчен түләүгә ставка | |
| | | сум/МВт·ай | сум/МВт·с | сум/кВт·с | сум/МВт·ай | сум/МВт·с | сум/кВт·с |
| 1 | «Энерготранзит» ҖЧҖе - «Сетевая компания» ААҖе | 383 538, 53 | 119,98 | 1,08239 | 383 538, 53 | 113,03 | 1,07543 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тарифлар буенча
карарларны кабул итүне оештыру, контрольдә
тоту һәм теркәү бүлеге